Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Яңа Троицкий авыл җирлегенең
Яңа Троицкий торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре
турындагы КАРАРЫ

26 ноябрь 2021 ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2021 елның 24 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта, 2021 елның 24 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә «Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Яңа Троицкий авыл җирлеге Яңа Троицкий авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: Яңа Троицкий авылы юлларын норматив хәлгә китерү, сметалар төзү, техник күзәтү үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләү?» соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 611 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 395 кеше, бу 64,6% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 386 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; гражданнар җыенында катнашучыларның 9 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Троицкий авыл җирлегенең Яңа Троицкий торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Троицкий авыл җирлегенең Яңа Троицкий авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, даими яшәүче булган һәр балигъ булган кешедән үзара салым средстволарын 2022 елда 400 сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган үзара салым средстволарын җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә: Яңа Троицкий авылы юлларын норматив хәлгә китерү, сметалар төзү, техник күзәтү үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләү.

4. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетысында бастырырга, Яңа Троицкий авылы, Совет урамы, 10 йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Н.Н. Лотфуллин